**СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы,
Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**« 2» сентябрь 2026 ел** **№ 37**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының “Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 24 октябрендәге 86 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2023 елның 25 апрелендәге 102 номерлы үзгәрешләр белән)**

“Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Арча муниципаль районының “Яңа Кенәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының “Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 24 октябрендәге 86 номерлы карары белән расланган (2023 елның 25 апрелендәге 102 номерлы үзгәрешләр белән) Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Депутатның вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш муниципаль берәмлекнең тулы хокуклы составындагы вәкиллекле органының беренче утырышын уздырган көннән туктатыла.”.

2. Әлеге мәгълүматны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Кенәр авыл
җирлеге башлыгы Ә.Ә.Гайфуллин